КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1044

2021 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында

2021 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планын (алга таба – План) расларга.

2. Планны тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертергә.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Планны тормышка ашыруда катнашучы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, аны үтәү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кертүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына 2021 елга Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм

бурычларны тормышка ашыру буенча чаралар күрергә һәм квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, аларны тормышка ашыру барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, алынган мәгълүматны гомумиләштерергә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин